ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.05.2017**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1273**

Муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукына аукцион уздыру турында

2006 елның 26 июлендәге «Конкуренцияне яклау турында» 135-ФЗ номерлы Федераль закон, 2010 елның 10 февралендәге «Аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль мөлкәткә карата хокукларның күчүен күздә тоткан башка шартнамәләр төзү хокукына бәйгеләр яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм күрсәтелгән шартнамәләрне төзү бәйге формасында торглар үткәрү юлы белән башкарыла торган мөлкәт төрләре исемлеге турында» 67 номерлы Россия Федераль монополиягә каршы хезмәте боерыгы нигезендә, муниципаль мөлкәтне нәтиҗәле файдалану максатларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының муниципаль мөлкәтне (алга таба - Мөлкәт) арендалау шартнамәсен төзү хокукына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә ,ачык аукцион үткәрергә.

2. Гамәлдәге законнар нигезендә, бәяләүченең хисабына туры китереп Мөлкәт өчен айлык аренда түләвенең башлангыч бәясен әлеге карар кушымтасында каралганча расларга.

3. түбәндәгеләрне билгеләргә:

3.1. Аукцион предметы булып Мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукы тора;

3.2. Мөлкәтне арендалау шартнамәсенең гамәлдә булу срогы кушымтада билгеләнгән;

3.3. Катнашучылар составы буенча аукцион: ачык;

3.4. Бәясе буенча тәкъдимнәр бирү ысулы: ачык;

3.5. Задатканың күләме 20 (егерме) % һәм хакының арту күләме (аукцион адымы) лотның башлангыч бәясеннән 5 (биш) % (НДСны исәпкә алмыйча).

3.6. Лотның иң югары бәясен тәкъдим иткән катнашучы аукционда җиңүче дип таныла;

3.7. Заявкалар кабул итү мәгълүмат хәбәрендә күрсәтелгән датадан башлана һәм ким дигәндә егерме календарь көн тәшкил итә.

4. «Интернет» челтәрендә «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең www.zelendolsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Россия Федерациясенең www.torgi.gov.ru рәсми сайтында сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен, гамәлдәге законнарда каралганча муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсен төзү хокукын сату буенча ачык аукцион үткәрү турында, аукционда катнашу өчен заявкалар бирү тәртибен, урынын һәм вакытын күрсәтеп, аның нәтиҗәләре, аны үткәрүдән баш тарту һәм аукционның башка шартлары турында мәгълүмати хәбәрләр бастырып чыгаруны тәэмин итәргә,

5. Сатуда җиңүче белән үткәрелгән ачык аукцион нәтиҗәләре буенча арендага бирелә торган Мөлкәткә аренда шартнамәсен төзергә.

6. «Татарстан Республикасы җир мөнәсәбәтләрен үстерү үзәге» ААҖнең махсуслаштырылган оешмасы аша аукцион уздыруны гамәлдәге законнар һәм 2016 елның 25 июлендәге 182 номерлы муниципаль контракт нигезендә оештырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Зеленодольск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МУ җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче А.Х.Сәхибуллин

Кушымта
Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
______________ №______________

Аукцион үткәрү юлы белән арендага тапшыруны күздә тоткан муниципаль мөлкәт исемлеге

| № т/б | Мөлкәт исеме | Адресы | Мәйданы (кв.м.) | Шартнамәнең башлангыч (минималь) бәясе (лот бәясе) - НДСтан башка айлык аренда өчен түләүнең базар хакы сумнарда (2016 елның 19 декабрендәге 4732-1216 номерлы хисап) | Арендага тапшырыла торган мөлкәтнең максатчан билгелеше | Аренда срогы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 1000 торак булмаган бина, 16:49:010216:1217 кадастр номерлы, 1нче подвал катлары | Татарстан Республикасы,Зеленодольск муниципаль районы, Зеленодольск шәһәре, Фрунзе ур., 1а йорты | 84,6 | 6 502 | Офис, склад, кибет | 5 ел |